Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР

КАРАР

21.11.2022 ел Менделеевск ш. №158

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителгән реклама конструкцияләрен урнаштыру хокукына сатулар әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Һөнәри керемгә салым” махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында” 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2022 елның 20 октябрендәге П06-72/2022 номерлы кисәтүен карап,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2015 елның 3 мартындагы 300 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителгән реклама конструкцияләрен урнаштыру хокукына сатулар әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 5 нче абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мөрәҗәгать итүче - билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик, физик зат, шәхси хуҗалык итүче субъект яисә үзмәшгуль; тәкъдим ителгән шартларда сату-алуларда катнашу өчен гариза биргән һәм сату уздыруга документация алган;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев